СОВЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО
ОБРАЗОВАНИЯ
«ЛЕНИНОГОРСКИЙ
МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН»
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
«ЛЕНИНОГОРСК
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ»
МУНИЦИПАЛЬ
БЕРӘМЛЕГЕ
СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

23.11.2023 г.Лениногорск № 79

Муниципаль милектә булган арендага алынган күчемсез милекне сатып алуга кече һәм урта эшкуарлык субъектларының өстенлекле хокукын гамәлгә ашырганда сатып алына торган милеккә түләүне өлешләп бирү срогын билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы, 2008 елның 22 июлендәге 159-ФЗ номерлы «Дәүләт милкендә яисә муниципаль милектә булган һәм кече һәм урта эшкуарлык субъектлары тарафыннан арендалана торган күчемсез мөлкәтне читләштерү үзенчәлекләре турында» Федераль законның 5 маддәсенең 1 нче өлеше, «Кече һәм урта эшкуарлык субъектларына мөлкәткә милек ярдәме күрсәтүне киңәйтү максатларында Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2018 елның 3 июлендәге 185-ФЗ номерлы федераль законнарга ярашлы рәвештә, «Лениногорск муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Советы КАРАР БИРДЕ:

1.Муниципаль милектәге һәм арендалана торган мөлкәтне сатып алуга өстенлекле хокукны гамәлгә ашырганда кече һәм урта эшкуарлык субъектлары сатып ала торган күчемсез мөлкәт өчен түләүне өлешләп түләү срогы 5 ел тәшкил итә, дип билгеләргә.

2. Арендалана торган мөлкәтне сатып алуга өстенлекле хокукны гамәлгә ашырганда муниципаль милектәге һәм кече һәм урта эшкуарлык субъектлары сатып ала торган күчемсез мөлкәтне түләү бертигез өлешләрдә айлык яисә квартал саен түләнә торган түләүләр юлы белән бер мәртәбә яисә өлешләп башкарыла.

3.Әлеге карарны Лениногорск муниципаль районының рәсми сайтында (http://leninogorsk.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга.

4. Әлеге карар рәсми басылып чыкканнан соң үз көченә керә.

5. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы «Мөлкәт һәм җир мөнәсәбәтләре палатасы» муниципаль берәмлегенең бюджет, салымнар, финанс, икътисад, инвестицияләр һәм эшкуарлык буенча комиссиясенә йөкләргә.

Лениногорск муниципаль
районы башлыгы,
Совет рәисе

Р.Г.Хөсәенов